Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге
Кычытканлы авылы торак пункты
гражданнар җыены КАРАРЫ

«22» ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлеге Кычытканлы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2023 елда 3200 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге торак пунктында су башнясы сатып алу һәм урнаштыру;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә суүткәргеч торбаларның аерым участокларын алыштыру һәм суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау;
-Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегендә янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авылында парк зонасын төзекләндерү.

Халык җыенында рәислек итүче Ф.Р. Сабиров

Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Сабиров